**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 26 июлендәге 472 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 26.07.2021 ел, № 472 карары белән расланган Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Регламентының 2.4.1 пунктындагы 3 абзацына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Әгәр җир кишәрлеген барлыкка китерергә тиешле җир кишәрлегенең урнашу схемасы "Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында" 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.5 статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булса, срок озайтылырга мөмкин, ләкин җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза кергән көннән алып утыз биш көннән дә артыкка түгел».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**